ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

01.03.2021

№ 246

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Җир эшләрен башкаруга ордер бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 8 декабрендәге 1543 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2020 елга Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын үтәү йомгаклары һәм 2021 елга республика финанс, казначылык һәм салым органнарының бурычлары буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе һәм Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсе уртак коллегиясенең 2021 елның 4 гыйнварындагы ПР-3 номерлы беркетмәсен үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Җир эшләрен башкаруга ордер бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 8 декабрендәге 1543 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Җир эшләрен башкаруга ордер бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентындагы 2 бүлекнең 2.5 пунктын түбәндәге эчтәлекле 6 пункт белән тулыландырырга:

«6. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмә.».

2. Әлеге карар рәсми төстә бастырып чыгарылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының ордер-рөхсәт бирү секторы мөдире Р.А. Гыйльмановка йөкләргә.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов